ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**Татарстан Республикасы Сайлау кодексына һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2021 елның 25 ноябрендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Сайлау кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2007, № 5, № 12 (I өлеш); 2010, № 6 (I өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2012, № 6 (I өлеш); 2013, № 10; 2014, № 5; 2015, № 5; 2016, № 4, № 6 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 27 (I өлеш), № 52 (I өлеш), № 55 (I өлеш); 2018, № 44 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 28 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 статьяга түбәндәге эчтәлекле $6^4$ өлеш өстәргә:

«$6^4$. «Экстремистлык эшчәнлегенә каршы тору турында» 2002 елның 25 июлендәге 114-ФЗ номерлы Федераль законда һәм «Террорчылыкка каршы тору турында» 2006 елның 6 мартындагы 35-ФЗ номерлы Федераль законда каралган нигезләр буенча иҗтимагый яисә дини берләшмәне, башка оешманы бетерү яисә аларның эшчәнлеген тыю турында суд карары (алга таба – экстремистлык яисә террорчылык оешмасын бетерү яисә аның эшчәнлеген тыю турында суд карары) законлы көченә кергән иҗтимагый яисә дини берләшмә, башка оешма эшчәнлегенә катнашы булган Россия Федерациясе гражданнарының сайлану хокуклары юк.

Әлеге чикләү экстремистлык яисә террорчылык оешмасының гамәлгә куючысы, коллегиаль җитәкче органы әгъзасы, җитәкчесе, җитәкче урынбасары, региональ яки башка структур бүлекчәсе җитәкчесе, региональ яки башка структур бүлекчәсе җитәкчесе урынбасары, катнашучысы, әгъзасы, хезмәткәре яисә экстремистлык яисә террорчылык оешмасы эшчәнлегенә катнашы булган башка зат булып торган затларга экстремистлык яисә террорчылык оешмасын бетерү яисә аның эшчәнлеген тыю турында суд карары законлы көченә кергән көнгә кадәр өч елдан алда башлана торган срокта – экстремистлык яисә террорчылык оешмасының

гамәлгә куючысы, коллегиаль җитәкче органы әгъзасы, җитәкчесе, җитәкче урынбасары, региональ яки башка структур бүлекчәсе җитәкчесе, региональ яки башка структур бүлекчәсе җитәкчесе урынбасарына, экстремистлык яисә террорчылык оешмасын бетерү яисә аның эшчәнлеген тыю турындагы суд карары законлы көченә кергән көнгә кадәр бер елдан алда башлана торган срокта – аның катнашучысы, әгъзасы, хезмәткәренә һәм экстремистлык яисә террорчылык оешмасы эшчәнлегенә катнашы булган башка затына, шулай ук күрсәтелгән суд карары законлы көченә кергәннән соң кагыла.

Әлеге өлеш нигезләмәләре экстремистлык яисә террорчылык оешмасы катнашучыларына, әгъзаларына, хезмәткәрләренә һәм законлы көченә кергән суд карары белән гамәлләрендә экстремистлык яисә террорчылык оешмасы эшчәнлегенә түбәндәге катнашы билгеләнгән башка затларга кагыла: тиешле оешманы экстремистлык яисә террорчылык оешмасы дип тану өчен сәбәп булган эшчәнлек максатларын һәм (яисә) рәвешләрен (шул исәптән аерым чараларны) турыдан-туры гамәлгә ашыру һәм (яисә) тиешле оешманы экстремистлык яисә террорчылык оешмасы дип тану өчен сәбәп булган эшчәнлек максатларын һәм (яисә) рәвешләрен (шул исәптән аерым чараларны) хуплавын сүзләр белән, шул исәптән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге гыйбарәләрне дә кертеп, йә башка гамәлләр аша (акчалата, мөлкәти, оештыру-методик, консультатив яисә башка ярдәм күрсәтү) белдерү.

Экстремистлык яисә террорчылык оешмасының гамәлгә куючысы, коллегиаль җитәкче органы әгъзасы, җитәкчесе, җитәкче урынбасары, региональ яисә башка структур бүлекчәсе җитәкчесе, региональ яисә башка структур бүлекчәсе җитәкчесе урынбасары булган затлар экстремистлык яисә террорчылык оешмасын бетерү яки аның эшчәнлеген тыю турындагы суд карары законлы көченә кергән көннән алып биш ел узганчы сайлана алмыйлар.

Экстремистлык яисә террорчылык оешмасының катнашучысы, әгъзасы, хезмәткәре яисә экстремистлык яисә террорчылык оешмасы эшчәнлегенә катнашы булган башка зат булган затлар экстремистлык яисә террорчылык оешмасын бетерү яисә эшчәнлеген тыю турындагы суд карары законлы көченә кергән көннән алып өч ел узганчы сайлана алмыйлар.»;

2) 12 статьяда:

а) түбәндәге эчтәлекле $8^1$ өлеш өстәргә:

«$8^1$. «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законда каралганча, әлеге статьяның 8 өлеше нигезендә Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тәкъдиме буенча билгеләнгән Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе әгъзасы вәкаләтләре комиссиянең шушы әгъзасын билгеләп куйган органга кертелгән Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясенең дәлилләнгән тәкъдиме буенча вакытыннан алда туктатылырга мөмкин. Комиссия әгъзасы вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турындагы тәкъдим белән бергә комиссиянең яңа әгъзасы кандидатурасы буенча тәкъдим дә кертелергә тиеш. Мондый тәкъдим булмаса, комиссия әгъзасы вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату

турында тәкъдим каралмый. Күрсәтелгән тәкъдим комиссия әгъзасы билгеләнгәннән соң бер ел эчендә, шулай ук Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе катнаша торган сайлау кампаниясе чорында, референдум кампаниясе чорында кертелә алмый.»;

б) түбәндәге эчтәлекле $10^2$ өлеш өстәргә:

«$10^2$. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына сайлаулар уздырганда, «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон нигезендә Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнгән тәртиптә массакүләм мәгълүмат чаралары, массакүләм коммуникацияләр, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә өлкәсендә контроль һәм күзәтчелек функцияләрен гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органына сайлаулар һәм референдумнар турында Россия Федерациясе законнары таләпләрен бозып әзерләнгән һәм (яисә) таратыла торган агитация материалларының, сайлаулар һәм референдумнар турында Россия Федерациясе законнарын бозып таратыла торган мәгълүматның мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләрендә, шул исәптән «Интернет» челтәрендә, таралуын булдырмый калу турында тәкъдим белән мөрәҗәгать итәргә хокуклы. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе, җирле үзидарә органнарына сайлаулар уздырганда, «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон нигезендә Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнгән тәртиптә массакүләм мәгълүмат чаралары, массакүләм коммуникацияләр, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә өлкәсендә контроль һәм күзәтчелек функцияләрен гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органына, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе тарафыннан җибәрелгән материалларга нигезләнеп, шундый тәкъдим белән мөрәҗәгать итәргә хокуклы.»;

3) 18 статьяда:

а) $6^2$ өлешкә түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тәкъдиме буенча билгеләнгән Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе әгъзасы, «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон нигезендә кертелгән Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясенең дәлилләнгән тәкъдименә нигезләнеп, үз вәкаләтләре чоры тәмамланганчы, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе әгъзасы вазыйфаларыннан азат ителергә мөмкин.»;

б) $10^1$ өлешнең беренче җөмләсендә «сәяси партия тарафыннан» сүзләрен төшереп калдырырга, «әлеге Кодексның 11 статьясындагы $4^2$ өлеше нигезендә» сүзләрен «әлеге Кодексның 11 статьясындагы $4^2$ өлеше яисә 12 статьясындагы $8^1$ өлеше нигезендә» сүзләренә алмаштырырга, түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп

гарантияләре турында» Федераль закон нигезендә вәкаләтләрне вакытыннан алда туктату турында тәкъдим кертелгән, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе әгъзасын билгеләп куйган орган әлеге өлеш нигезендә кабул ителгән карар турында Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясенә хәбәр итә.»;

4) 39 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 4 пункт өстәргә:

«4) әгәр кандидат чит ил агенты функциясен башкаручы физик зат яисә чит ил агенты функциясен башкаручы зат белән аффилиацияләнгән кандидат булса, – бу хакта белешмәләр.»;

5) 44 статьяның 7 өлешенә түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Әгәр кандидат чит ил агенты функциясен башкаручы физик зат яисә чит ил агенты функциясен башкаручы зат белән аффилиацияләнгән кандидат булса, бу хакта белешмәләр имза кәгазендә күрсәтелгән булырга тиеш. Составында шундый кандидат күрсәтелгән кандидатлар исемлеген күрсәтүне хуплап имзалар җыю очрагында, имза кәгазендә әлеге сайлау берләшмәсе тарафыннан чит ил агенты функциясен башкаручы кандидат (кандидатлар) һәм (яисә) чит ил агенты функциясен башкаручы зат белән аффилиацияләнгән кандидат (кандидатлар) күрсәтелү турындагы мәгълүмат бирелә.»;

6) 45 статьяның 3 өлешендәге 4 пунктының «е[1]» пунктчасында «2 статьясындагы» сүзләрен «3 статьясындагы» сүзләренә алмаштырырга, «2012 елның 3 декабрендәге 229-ФЗ номерлы» сүзләрен «2020 елның 22 декабрендәге 439-ФЗ номерлы» сүзләренә алмаштырырга, «3 өлешендәге» сүзләрен «4 өлешендәге» сүзләренә алмаштырырга;

7) 46 статьяның 5 өлешенә «белешмәләрне» сүзеннән соң «, шул исәптән кандидатның чит ил агенты функциясен башкаручы физик зат йә чит ил агенты функциясен башкаручы зат белән аффилиацияләнгән кандидат булуы турындагы белешмәләрне,» сүзләрен өстәргә;

8) 55 статьяга түбәндәге эчтәлекле 5[1] өлеш өстәргә:

«5[1]. Комиссияләр, шулай ук массакүләм мәгълүмат чараларын чыгаруны гамәлгә ашыручы оешмалар, челтәр басмалары редакцияләре сайлаучыларга чит ил агенты функциясен башкаручы физик зат булып торучы кандидат турында йә чит ил агенты функцияләрен башкаручы зат белән аффилиацияләнгән кандидат турында хәбәр иткәндә, кандидатның чит ил агенты функциясен башкаручы физик зат яисә чит ил агенты функциясен башкаручы кандидат белән аффилиацияләнгән кандидат булуы күрсәтелергә тиеш.»;

9) 58 статьяда:

а) 4 өлешнең 3 пунктында «бастырып чыгару һәм тарату юлы белән» сүзләрен «эшләү һәм тарату юлы белән, шул исәптән мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләрендә, «Интернет» челтәрен дә кертеп» сүзләренә алмаштырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле $4^1$ өлеш өстәргә:

«$4^1$. «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законда каралганча, агитация материалларын эшләү һәм (яисә) тарату үзенчәлекләре, сайлаулар һәм референдумнар турында Россия Федерациясе законнары таләпләрен исәпкә алып, Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнергә мөмкин.»;

в) түбәндәге эчтәлекле $10^3$ өлеш өстәргә:

«$10^3$. Чит ил агенты функцияләрен башкаручы физик зат булып торган кандидатның, чит ил агенты функцияләрен башкаручы зат белән аффилиацияләнгән кандидатның агитация материалында әлеге кандидатның чит ил агенты функцияләрен башкаручы физик зат йә чит ил агенты функцияләрен башкаручы зат белән аффилиацияләнгән кандидат булуы турында мәгълүмат булырга тиеш. Тиешле сайлауларда чит ил агенты функцияләрен башкаручы физик зат йә чит ил агенты функцияләрен башкаручы зат белән аффилиацияләнгән кандидат булып торган кандидатны күрсәткән (шул исәптән кандидатлар исемлеге составында) сайлау берләшмәсенең агитация материалында сайлау берләшмәсе тарафыннан мондый кандидат күрсәтелү (шул исәптән кандидатлар исемлеге составында) турында мәгълүмат булырга тиеш. Әлеге мәгълүмат ачыктан-ачык күренеп торырга (аңлаешлы ишетелергә) һәм агитация материалы мәйданының (күләменең) кимендә 15 процентын биләргә тиеш.»;

10) 59 статьяда:

а) 1 өлештә «сәгатендә» сүзеннән соң «, ә әлеге Кодексның $75^1$ статьясындагы 1 яисә 2 өлешендә каралган тавыш бирүне берничә көн рәттән үткәрү турындагы карар кабул ителгән очракта – тавыш бирүнең беренче көненең җирле вакыт белән ноль сәгатендә» сүзләрен өстәргә;

б) 2 өлештә «сәгатендә» сүзеннән соң «, ә әлеге Кодексның $75^1$ статьясындагы 1 яисә 2 өлешендә каралган тавыш бирүне берничә көн рәттән үткәрү турындагы карар кабул ителгән очракта – тавыш бирүнең беренче көненең җирле вакыт белән ноль сәгатендә» сүзләрен өстәргә;

в) 3 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Тавыш бирү көнендә сайлау алды агитациясен үткәрү тыела.

Әлеге Кодексның $75^1$ статьясындагы 1 яисә 2 өлешендә каралган тавыш бирүне берничә көн рәттән үткәрү турындагы карар кабул ителү очрагыннан тыш, тавыш бирү көненә кадәрге көндә сайлау алды агитациясен үткәрү тыела.»;

11) 61 статьяның $4^1$ өлешенә түбәндәге эчтәлекле җөмләләр өстәргә: «Уртак агитация чарасында чит ил агенты функцияләрен башкаручы физик зат булып торучы теркәлгән кандидат йә чит ил агенты функцияләрен башкаручы зат белән аффилиацияләнгән теркәлгән кандидат катнашкан очракта, аның чыгышында әлеге кандидатның чит ил агенты функцияләрен башкаручы физик зат йә чит ил агенты функцияләрен башкаручы зат белән аффилиацияләнгән кандидат булуы турындагы мәгълүмат әйтелергә (бирелергә) тиеш. Уртак агитация чарасында тиешле

сайлауларда чит ил агенты функцияләрен башкаручы физик зат йә чит ил агенты функцияләрен башкаручы зат белән аффилиацияләнгән кандидатны күрсәткән (шул исәптән кандидатлар исемлеге составында) сайлау берләшмәсе тарафыннан күрсәтелгән теркәлгән кандидат катнашкан очракта, аның чыгышында сайлау берләшмәсе тарафыннан мондый кандидат күрсәтелү турында мәгълүмат әйтелергә (бирелергә) тиеш.»;

12) 62 статьяның 12 өлешенә түбәндәге эчтәлекле яңа өченче җөмлә өстәргә: «Чит ил агенты функцияләрен башкаручы физик зат булып торучы кандидатның, чит ил агенты функцияләрен башкаручы зат белән аффилиацияләнгән кандидатның яисә тиешле сайлауларда мондый кандидатны (мондый кандидатларны) күрсәткән (шул исәптән кандидатлар исемлеге составында) сайлау берләшмәсенең вакытлы басма матбугатларда урнаштырыла торган агитация материалларында әлеге Кодексның 58 статьясындагы $10^3$ өлеше нигезендә кандидатның чит ил агенты функцияләрен башкаручы физик зат булуы йә чит ил агенты функцияләрен башкаручы зат белән аффилиацияләнгән кандидат булуы турында яисә сайлау берләшмәсе тарафыннан мондый кандидат (кандидатлар) күрсәтелү (шул исәптән кандидатлар исемлеге составында) турында мәгълүмат урнаштырылырга тиеш.»;

13) 64 статьяда:

а) исемендә «чыгару» сүзен «эшләү» сүзенә алмаштырырга;

б) 1 өлештә «таратырга» сүзеннән соң «, шул исәптән мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләрендә, «Интернет» челтәрен дә кертеп,» сүзләрен өстәргә;

в) 3 өлештә «басылып чыгу» сүзләрен «эшләнү» сүзенә алмаштырырга, түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Чит ил агенты функцияләрен башкаручы физик зат булып торучы кандидатның, чит ил агенты функцияләрен башкаручы зат белән аффилиацияләнгән кандидатның, мондый кандидатны тиешле сайлауларда (шул исәптән кандидатлар исемлеге составында) күрсәткән сайлау берләшмәсенең барлык агитация материалларында әлеге Кодексның 58 статьясындагы $10^3$ өлеше нигезендә бу хакта мәгълүмат булырга тиеш.»;

г) 4 өлештә «нөсхәләре,» сүзен «нөсхәләре яисә күчермәләре,» сүзләренә алмаштырырга, «яисә нөсхәләре» сүзләрен «, нөсхәләре яисә күчермәләре» сүзләренә алмаштырырга;

д) 7 өлештә «58 статьясындагы 10 өлешендә» сүзләрен «58 статьясындагы 10 һәм $10^3$ өлешләрендә» сүзләренә алмаштырырга;

е) 12 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12. Әлеге статья нигезләмәләре, әлеге Кодексның 61 һәм 62 статьялары нигезендә таратыла торган агитация материалларыннан тыш, басма, аудиовизуаль һәм башка агитация материалларын, шул исәптән мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләрендә, «Интернет» челтәрен дә кертеп, тарату өчен эшләнгәннәрен һәм таратыла торганнарын, эшләүгә һәм таратуга карата кулланыла.»;

14) 66 статьяның 12 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12. Сайлауларны әзерләүгә һәм уздыруга бәйле товарлар, эшләр яисә хезмәтләр күрсәтү сатып алулар тиешле сайлауларны оештыручы комиссия яисә аның карары нигезендә түбәндәге тиешле комиссияләр тарафыннан «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗлар өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр күрсәтү сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, ә күрсәтелгән Федераль закон кулланылмый торган мөнәсәбәтләр өлешендә – Россия Федерациясе Граждан кодексы нигезендә гамәлгә ашырыла.»;

15) 67 статьяның 14 өлешендәге 14 пунктына «, чит ил агенты функцияләрен башкаручы чит ил массакүләм мәгълүмат чаралары реестрына мәгълүмат кертелгән Россия юридик затлары» сүзләрен өстәргә;

16) 68 статьяда:

а) 1 өлешкә түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Чит ил агенты функцияләрен башкаручы физик затлар исемлегенә кертелгән һәм (яисә) аның турында мәгълүмат чит ил агенты функцияләрен башкаручы чит ил массакүләм мәгълүмат чаралары реестрына кертелгән граждан иганә керткәндә, мондый граждан түләү документында бу хакта белешмәләр күрсәтә.»;

б) 5 өлештә «дөрес» сүзеннән соң «яисә тулысынча» сүзләрен өстәргә, «законлы» сүзеннән соң «яисә иганәче турында белешмәләрнең тулы» сүзләрен өстәргә;

17) 73 статьяның 4 өлешенә түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Әгәр теркәлгән кандидат, шул исәптән кандидатлар исемлеге составында, чит ил агенты функцияләрен башкаручы физик зат йә чит ил агенты функцияләрен башкаручы зат белән аффилиацияләнгән кандидат булып торса, мәгълүмат стендында бу хакта мәгълүмат урнаштырыла.»;

18) 75 статьяда:

а) түбәндәге эчтәлекле $8^1$ өлеш өстәргә:

«$8^1$. Бюллетеньгә уннан артык теркәлгән кандидат кертелгән очракта, сайлауларны оештыручы сайлау комиссиясе, Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе белән килештереп, әлеге статьяның 6 өлешендәге 4 һәм 5 пунктларында, 7 өлешендә каралган теркәлгән кандидатларның һәркайсы турында белешмәләрнең (барлык белешмәләрнең йә кайберләренең) бюллетеньдә урнаштырылмавы һәм сайлауларны оештыручы сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнгән форма буенча эшләнә торган махсус мәгълүмат материалында күрсәтелүе турында карар кабул итәргә хокуклы. Әлеге мәгълүмат материалы кабинада йә яшерен тавыш бирү өчен махсус җиһазландырылган башка урында һәм (яисә) әлеге Кодексның 73 статьясындагы 3 өлешендә күрсәтелгән мәгълүмат стендында урнаштырыла.»;

б) түбәндәге эчтәлекле $9^1$ өлеш өстәргә:

«$9^1$. Бюллетеньгә уннан артык теркәлгән кандидатлар исемлеге кертелгән очракта, сайлауларны оештыручы сайлау комиссиясе, Россия Федерациясе Үзәк

сайлау комиссиясе белән килештереп, әлеге статьяның 9 өлешендә күрсәтелгән кандидатларның фамилияләре, исемнәре, аталарының исемнәре бюллетеньдә урнаштырылмый һәм сайлауларны оештыручы сайлау комиссиясе билгеләгән рәвештә эшләнә торган махсус мәгълүмат материалында күрсәтелә дигән карар кабул итәргә хокуклы. Әлеге мәгълүмат материалы кабинада йә яшерен тавыш бирү өчен махсус җиһазландырылган башка урында һәм (яисә) әлеге Кодексның 73 статьясындагы 3 өлешендә күрсәтелгән мәгълүмат стендында урнаштырыла.»;

в) түбәндәге эчтәлекле $10^1$ өлеш өстәргә:

«$10^1$. Әгәр сайлау бюллетененә кертелгән теркәлгән кандидат чит ил агенты функцияләрен башкаручы физик зат йә чит ил агенты функцияләрен башкаручы зат белән аффилиацияләнгән кандидат булып торса, сайлау бюллетенендә кандидатның чит ил агенты функцияләрен башкаручы физик зат яисә чит ил агенты функцияләрен башкаручы зат белән аффилиацияләнгән кандидат булуы турында белешмәләр күрсәтелергә тиеш. Мондый кандидат (кандидатлар) кандидатлар исемлеге составына кертелгән һәм аның (алар) турында белешмәләр әлеге статьяның 9 өлеше нигезендә сайлау бюллетененә кертелмәгән очракта, сайлау бюллетенендә кандидатлар исемлеге составында мондый кандидат (кандидатлар) күрсәтелде дип билгеләнә.»;

19) 77 статьяның $8^1$ өлешендәге беренче абзацында «8 өлешендәге 1 һәм 2 пунктларында» сүзләрен «8 өлешендә» сүзләренә алмаштырырга, «1 күчерелмә әрҗәдән» сүзләрен «2 күчерелмә әрҗәдән» сүзләренә алмаштырырга;

20) 1 нче кушымтада:

а) таблицага 3, 4 һәм 5 юллар өстәргә;

б) искәрмәне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Искәрмә. Әгәр имза кәгазендә белешмәләре күрсәтелә торган кандидат элек яисә хәзер хөкем ителгән булса, имза кәгазендә кандидатның атасы исеменнән соң кандидатның хөкем ителүе турында белешмәләр күрсәтелә. Әгәр кандидат чит ил агенты функцияләрен башкаручы физик зат йә чит ил агенты функцияләрен башкаручы зат белән аффилиацияләнгән кандидат булып торса, имза кәгазендә кандидатның атасы исеменнән соң (кандидат шулай ук элек яисә хәзер хөкем ителгән очракта – хөкем ителүе турында белешмәләрдән соң) кандидатның чит ил агенты функцияләрен башкаручы физик зат йә чит ил агенты функцияләрен башкаручы зат белән аффилиацияләнгән кандидат булуы хакында белешмәләр күрсәтелә. Әгәр имза кәгазендә белешмәләре булган кандидат Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 39 статьясындагы 6 өлеше һәм 41 статьясындагы 2 өлеше нигезендә күрсәтелергә ризалыгы турындагы гаризада кайсы сәяси партиягә йә бүтән иҗтимагый берләшмәгә каравын һәм әлеге сәяси партиядәге йә әлеге иҗтимагый берләшмәдәге үзенең статусын күрсәтсә, бу хакта белешмәләр имза кәгазендә кандидатның яшәү урыны турындагы белешмәләрдән соң яисә кандидатның хөкем ителүе турындагы белешмәләрдән соң, ә кандидат чит ил агенты функцияләрен башкаручы физик зат йә чит ил агенты функцияләрен башкаручы зат белән аффилиацияләнгән кандидат булып торса, шул хактагы

белешмәләрдән соң бирелә. Имза кәгазе бары тик бер яктан гына тутыру өчен эшләнә, һәм анда сайлаучылар имзаларын кую өчен биш юл булырга тиеш.».

**2 статья**

«Татарстан Республикасы референдумы турында» 2003 елның 9 августындагы 33-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 8; 2005, № 3 (I өлеш); 2008, № 6; 2010, № 10 (II өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2013, № 10; 2014, № 5; 2015 № 5; 2016, № 6 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 44 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2019, № 28 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш); 2021, № 29 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 17 статьяда:

а) беренче абзацта «Референдум әзерләгәндә» сүзләрен «1. Референдум әзерләгәндә» сүзләренә алмаштырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле 2 пункт өстәргә:

«2. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе, референдум уздырганда, Федераль закон нигезендә Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнгән тәртиптә массакүләм мәгълүмат чаралары, массакүләм коммуникацияләр, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә өлкәсендә контроль һәм күзәтчелек функцияләрен гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органына сайлаулар һәм референдумнар турында Россия Федерациясе законнары таләпләрен бозып эшләнгән һәм (яисә) таратыла торган агитация материалларының, сайлаулар һәм референдумнар турында Россия Федерациясе законнарын бозып таратыла торган мәгълүматның мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләрендә, шул исәптән «Интернет» челтәрендә, таралуын булдырмый калу турында тәкъдим белән мөрәҗәгать итәргә хокуклы.»;

2) 34 статьяда:

а) 2 пунктның «в» пунктчасында «бастырып чыгару һәм тарату юлы белән» сүзләрен «эшләү һәм тарату юлы белән, шул исәптән мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләрендә, «Интернет» челтәрен дә кертеп» сүзләренә алмаштырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле $2^1$ пункт өстәргә:

«$2^1$. Федераль законда каралганча, агитация материалларын эшләү һәм (яисә) тарату үзенчәлекләре, сайлаулар һәм референдумнар турында Россия Федерациясе законнары таләпләрен исәпкә алып, Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнергә мөмкин.»;

3) 35 статьяда:

а) 1 пунктта «сәгатендә» сүзеннән соң «, ә әлеге Законның $49^1$ статьясындагы 1 яисә 2 пунктында каралган тавыш бирүне берничә көн рәттән үткәрү турындагы карар кабул ителгән очракта – тавыш бирүнең беренче көненең җирле вакыт белән ноль сәгатендә» сүзләрен өстәргә;

б) 2 пунктта «сәгатендә» сүзеннән соң «, ә әлеге Законның 49[1] статьясындагы 1 яисә 2 пунктында каралган тавыш бирүне берничә көн рәттән үткәрү турындагы карар кабул ителгән очракта – тавыш бирүнең беренче көненең җирле вакыт белән ноль сәгатендә» сүзләрен өстәргә;

в) 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Тавыш бирү көнендә референдум мәсьәләләре буенча агитация үткәрү тыела.

Әлеге Законның 49[1] статьясындагы 1 яисә 2 пунктында каралган тавыш бирүне берничә көн рәттән үткәрү турындагы карар кабул ителү очрагыннан тыш, тавыш бирү көненә кадәрге көндә референдум мәсьәләләре буенча агитация үткәрү тыела.»;

4) 40 статьяда:

а) исемендә «чыгару» сүзен «эшләү» сүзенә алмаштырырга;

б) 1 пунктта «таратырга» сүзеннән соң «, шул исәптән мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләрендә, «Интернет» челтәрен дә кертеп,» сүзләрен өстәргә;

в) 2 пунктта «бастырып чыгару» сүзләрен «эшләнү» сүзенә алмаштырырга;

г) 3 пунктта «нөсхәләре,» сүзен «нөсхәләре яисә күчермәләре» сүзләренә алмаштырырга, «яисә нөсхәләре» сүзләрен «, нөсхәләре яисә күчермәләре» сүзләренә алмаштырырга;

д) 11 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11. Әлеге статья нигезләмәләре, әлеге Законның 37 һәм 38 статьялары нигезендә таратыла торган агитация материалларыннан тыш, басма, аудиовизуаль һәм башка агитация материалларын, шул исәптән мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләрендә, «Интернет» челтәрен дә кертеп, тарату өчен эшләнгәннәрен һәм таратыла торганнарын, эшләүгә һәм таратуга карата кулланыла.»;

5) 43 статьяның 9 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9. Референдум әзерләүгә һәм үткәрүгә бәйле товарлар, эшләр яисә хезмәтләр күрсәтү сатып алулар Федераль законда каралган тәртиптә гамәлгә ашырыла.»;

6) 44 статьяда:

а) 5 пунктның «о» пунктчасына «, чит ил агенты функцияләрен башкаручы чит ил массакүләм мәгълүмат чаралары реестрына мәгълүмат кертелгән Россия юридик затлары» сүзләрен өстәргә;

б) 6 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Чит ил агенты функцияләрен башкаручы физик затлар исемлегенә кертелгән һәм (яисә) аның турында мәгълүмат чит ил агенты функцияләрен башкаручы чит ил массакүләм мәгълүмат чаралары реестрына кертелгән граждан иганә керткәндә, мондый граждан түләү документында бу хакта белешмәләр күрсәтә.»;

в) 8 пунктта «күрсәткән очракта» сүзләрен «күрсәткән һәм белешмәләр дөрес яисә тулы булмаган очракта» сүзләренә алмаштырырга;

7) 51 статьяның $8^1$ пунктындагы беренче абзацында «8 пунктындагы «а» һәм «б» пунктчаларында» сүзләрен «8 пунктында» сүзләренә алмаштырырга, «1 күчерелмә әрҗәдән» сүзләрен «2 күчерелмә әрҗәдән» сүзләренә алмаштырырга.

**3 статья**

«Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 3 (II өлеш); 2005, № 3 (I өлеш); 2008, № 5 (II өлеш); 2010, № 10 (II өлеш); 2011, № 8, № 12; 2013, № 10; 2014, № 5; 2015, № 5; 2016, № 6 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 44 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2019, № 28 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш); 2021, № 29 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 36 статьяда:

а) 2 пунктның «в» пунктчасында «бастырып чыгару һәм тарату юлы белән» сүзләрен «эшләү һәм тарату юлы белән, шул исәптән мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләрендә, «Интернет» челтәрен дә кертеп» сүзләренә алмаштырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле $2^1$ пункт өстәргә:

«$2^1$. «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законда каралганча, агитация материалларын эшләү һәм (яисә) тарату үзенчәлекләре, сайлаулар һәм референдумнар турында Россия Федерациясе законнары таләпләрен исәпкә алып, Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнергә мөмкин.»;

в) түбәндәге эчтәлекле 11 пункт өстәргә:

«11. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе, референдум уздырганда, «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон нигезендә Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнгән тәртиптә массакүләм мәгълүмат чаралары, массакүләм коммуникацияләр, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә өлкәсендә контроль һәм күзәтчелек функцияләрен гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органына, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе тарафыннан җибәрелгән материалларга нигезләнеп, сайлаулар һәм референдумнар турында Россия Федерациясе законнары таләпләрен бозып эшләнгән һәм (яисә) таратыла торган агитация материалларының, сайлаулар һәм референдумнар турында Россия Федерациясе законнарын бозып таратыла торган мәгълүматның мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләрендә, шул исәптән «Интернет» челтәрендә, таралуын булдырмый калу турында тәкъдим белән мөрәҗәгать итәргә хокуклы.»;

2) 37 статьяда:

а) 1 пунктта «сәгатендә» сүзеннән соң «, ә әлеге Законның $51^1$ статьясындагы 1 яисә 2 пунктында каралган тавыш бирүне берничә көн рәттән үткәрү турындагы

карар кабул ителгән очракта – тавыш бирүнең беренче көненең җирле вакыт белән ноль сәгатендә» сүзләрен өстәргә;

б) 2 пунктта «сәгатендә» сүзеннән соң «, ә әлеге Законның $51^1$ статьясындагы 1 яисә 2 пунктында каралган тавыш бирүне берничә көн рәттән үткәрү турындагы карар кабул ителгән очракта – тавыш бирүнең беренче көненең җирле вакыт белән ноль сәгатендә» сүзләрен өстәргә;

в) 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Тавыш бирү көнендә референдум мәсьәләләре буенча агитация үткәрү тыела.

Әлеге Законның $51^1$ статьясындагы 1 яисә 2 пунктында каралган тавыш бирүне берничә көн рәттән үткәрү турындагы карар кабул ителү очрагыннан тыш, тавыш бирү көненә кадәрге көндә референдум мәсьәләләре буенча агитация үткәрү тыела.»;

3) 42 статьяда:

а) исемендә «чыгару» сүзен «эшләү» сүзенә алмаштырырга;

б) 1 пунктта «таратырга» сүзеннән соң «, шул исәптән мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләрендә, «Интернет» челтәрен дә кертеп,» сүзләрен өстәргә;

в) 2 пунктта «чыгару» сүзен «эшләнү» сүзенә алмаштырырга;

г) 3 пунктта «нөсхәләре,» сүзен «нөсхәләре яисә күчермәләре» сүзләренә алмаштырырга, «яисә нөсхәләре» сүзләрен «, нөсхәләре яисә күчермәләре» сүзләренә алмаштырырга;

д) 11 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11. Әлеге статья нигезләмәләре, әлеге Законның 39 һәм 40 статьялары нигезендә таратыла торган агитация материалларыннан тыш, басма, аудиовизуаль һәм башка агитация материалларын, шул исәптән мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләрендә, «Интернет» челтәрен дә кертеп, тарату өчен эшләнгәннәрен һәм таратыла торганнарын, эшләүгә һәм таратуга карата кулланыла.»;

4) 45 статьяның 10 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10. Референдум әзерләүгә һәм үткәрүгә бәйле товарлар, эшләр яисә хезмәтләр күрсәтү сатып алулар «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законда каралган тәртиптә гамәлгә ашырыла.»;

5) 46 статьяда:

а) 5 пунктның «о» пунктчасына «, чит ил агенты функцияләрен башкаручы чит ил массакүләм мәгълүмат чаралары реестрына мәгълүмат кертелгән Россия юридик затлары» сүзләрен өстәргә;

б) 6 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Чит ил агенты функцияләрен башкаручы физик затлар исемлегенә кертелгән һәм (яисә) аның турында мәгълүмат чит ил агенты функцияләрен башкаручы чит ил

массакүләм мәгълүмат чаралары реестрына кертелгән граждан иганә керткәндә, мондый граждан түләү документында бу хакта белешмәләр күрсәтә.»;

в) 8 пунктта «белешмәләрне һәм дөрес булмаган белешмәләрне күрсәткән очракта» сүзләрен «белешмәләрне күрсәткән һәм алар дөрес яисә тулы булмаган очракта» сүзләренә алмаштырырга;

б) 53 статьяның $8^1$ пунктындагы беренче абзацында «8 пунктындагы «а» һәм «б» пунктчаларында» сүзләрен «8 пунктында» сүзләренә алмаштырырга, «1 кучерелмә әрҗәдән» сүзләрен «2 кучерелмә әрҗәдән» сүзләренә алмаштырырга.

**4 статья**

«Татарстан Республикасы Президентын чакыртып алу тәртибе турында» 2012 елның 25 декабрендәге 92-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 12 (II өлеш); 2014, № 5; 2015, № 5; 2016, № 6 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 44 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2019, № 28 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш); 2021, № 29 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 18 статьяда:

а) беренче абзацта «Чакыртып алу буенча» сүзләрен «1. Чакыртып алу буенча» сүзләренә алмаштырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле 2 өлеш өстәргә:

«2. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе, чакыртып алу буенча тавыш бирүне уздырганда, «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон нигезендә Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнгән тәртиптә массакүләм мәгълүмат чаралары, массакүләм коммуникацияләр, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә өлкәсендә контроль һәм күзәтчелек функцияләрен гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органына сайлаулар һәм референдумнар турында Россия Федерациясе законнары таләпләрен бозып эшләнгән һәм (яисә) таратыла торган агитация материалларының, сайлаулар һәм референдумнар турында Россия Федерациясе законнарын бозып таратыла торган мәгълүматның мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләрендә, шул исәптән «Интернет» челтәрендә, таралуын булдырмый калу турында тәкъдим белән мөрәҗәгать итәргә хокуклы.»;

2) 31 статьяда:

а) 2 өлешнең 3 пунктында «бастырып чыгару һәм тарату юлы белән» сүзләрен «эшләү һәм тарату юлы белән, шул исәптән мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләрендә, «Интернет» челтәрен дә кертеп» сүзләренә алмаштырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле $2^1$ өлеш өстәргә:

«$2^1$. «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законда

каралганча, агитация материалларын эшләү һәм (яисә) тарату үзенчәлекләре, сайлаулар һәм референдумнар турында Россия Федерациясе законнары таләпләрен исәпкә алып, Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнергә мөмкин.»;

3) 32 статьяда:

а) 1 өлештә «сәгатьтә» сүзеннән соң «, ә әлеге Законның 45[1] статьясындагы 1 яисә 2 өлешендә каралган тавыш бирүне берничә көн рәттән үткәрү турындагы карар кабул ителгән очракта – тавыш бирүнең беренче көнендә җирле вакыт белән ноль сәгатьтә» сүзләрен өстәргә;

б) 2 өлештә «сәгатьтә» сүзеннән соң «, ә әлеге Законның 45[1] статьясындагы 1 яисә 2 өлешендә каралган тавыш бирүне берничә көн рәттән үткәрү турындагы карар кабул ителгән очракта – тавыш бирүнең беренче көнендә җирле вакыт белән ноль сәгатьтә» сүзләрен өстәргә;

в) 3 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Тавыш бирү көнендә чакыртып алу мәсьәләләре буенча агитация үткәрү тыела.

Әлеге Законның 45[1] статьясындагы 1 яисә 2 өлешендә каралган тавыш бирүне берничә көн рәттән үткәрү турындагы карар кабул ителү очрагыннан тыш, тавыш бирү көненә кадәрге көндә чакыртып алу мәсьәләләре буенча агитация үткәрү тыела.»;

4) 37 статьяда:

а) исемендә «чыгару» сүзен «эшләү» сүзенә алмаштырырга;

б) 1 өлештә «таратырга» сүзеннән соң «, шул исәптән мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләрендә, «Интернет» челтәрен дә кертеп,» сүзләрен өстәргә;

в) 3 өлештә «басылып чыгу» сүзләрен «эшләнү» сүзенә алмаштырырга;

г) 4 өлештә «нөсхәләре,» сүзен «нөсхәләре яисә күчермәләре,» сүзләренә алмаштырырга, «яисә нөсхәләре» сүзләрен «, нөсхәләре яисә күчермәләре» сүзләренә алмаштырырга;

д) 11 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11. Әлеге статья нигезләмәләре, әлеге Законның 34 һәм 35 статьялары нигезендә таратыла торган агитация материалларыннан тыш, басма, аудиовизуаль һәм башка агитация материалларын, шул исәптән мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләрендә, «Интернет» челтәрен дә кертеп, тарату өчен эшләнгәннәрен һәм таратыла торганнарын, эшләүгә һәм таратуга карата кулланыла.»;

5) 39 статьяның 7 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Чакыртып алу буенча тавыш бирүне әзерләүгә һәм үткәрүгә бәйле товарлар, эшләр яисә хезмәтләр күрсәтү сатып алулар «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законда каралган тәртиптә гамәлгә ашырыла.»;

6) 40 статьяда:

а) 5 өлешнең 14 пунктына «, чит ил агенты функцияләрен башкаручы чит ил массакүләм мәгълүмат чаралары реестрына мәгълүмат кертелгән Россия юридик затлары» сүзләрен өстәргә;

б) 7 өлешкә түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Чит ил агенты функцияләрен башкаручы физик затлар исемлегенә кертелгән һәм (яисә) аның турында мәгълүмат чит ил агенты функцияләрен башкаручы чит ил массакүләм мәгълүмат чаралары реестрына кертелгән граждан иганә керткәндә, мондый граждан түләү документында бу хакта белешмәләр күрсәтә.»;

в) 9 өлештә «җитәрлек» сүзеннән соң «яисә тулы» сүзләрен өстәргә;

7) 47 статьяның 9 өлешендәге беренче абзацында «8 өлешендәге 1 һәм 2 пунктларында» сүзләрен «8 өлешендә» сүзләренә алмаштырырга, «1 күчерелмә әрҗәдән» сүзләрен «2 күчерелмә әрҗәдән» сүзләренә алмаштырырга.

**5 статья**

1. Әлеге Закон, бу статьяда үз көченә керүнең башка сроклары билгеләнгән нигезләмәләреннән тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 14 пункты, 2 статьясындагы 5 пункты, 3 статьясындагы 4 пункты һәм 4 статьясындагы 5 пункты 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК / ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2021 ел, 11 декабрь
№ 90-ТРЗ